ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

28.02.2020 ел Баулы шәһәре №34

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенең
2015 елның 4 мартындагы 44 номерлы
карары белән расланган Баулы
муниципаль районында финанс-бюджет
өлкәсендә контроль буенча
вәкаләтләрне гамәлгә ашыру
тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 27 декабрендәге 449-ФЗ номерлы Федераль закон, «Эчке дәүләт (муниципаль) финанс контролен гамәлгә ашырганда эчке дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнарының һәм эчке дәүләт (муниципаль) финанс контроле объектларының (аларның вазыйфаи затларының) хокуклары һәм бурычлары» эчке дәүләт (муниципаль) финанс контроле федераль стандартын раслау турында»гы 2020 елның 6 февралендәге 100 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2015 елның 4 мартындагы 44 номерлы карары белән расланган Баулы муниципаль районында финанс-бюджет өлкәсендә контроль буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 пунктта:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында»гы 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы нигезендә билгеләнгән сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру кагыйдәләрен үтәү»;

җиденче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

сигезенче абзацны җиденче абзац дип санарга һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законда каралган контрактны үтәүгә, үзгәртүгә, шулай ук контракт шартларын үтәүгә, шул исәптән товарның, башкарылган эшнең (аның нәтиҗәсенең) яки күрсәтелгән хезмәтнең контракт шартларына туры килү-килмәве өлешендә, контракт шартларын үтәү таләпләрен үтәүне;»;

тугызынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Әлеге Тәртипнең 9 пунктында күрсәтелгән вазыйфаи затлар хокуклы:

а) нигезләнгән запрос нигезендә язмача яки телдән мәгълүмат, документлар һәм материаллар, шулай ук тикшерүләр, ревизияләр һәм тикшеренүләр (алга таба-контроль чаралар) үткәрү ечен аларның кирәкле күчермәләрен соратып алырга һәм алырга;

б) контроль объектыннан контроль чаралар үткәрү өчен кирәкле язмача яки телдән аңлатмалар алырга;

в) күчмә тикшерүләр (ревизияләр) барышында шәхесне таныклаучы документ (хезмәт таныклыгы) һәм контроль чара үткәрү турында контроль органы хокукый актының күчермәләрен күрсәтеп, тоткарлыксыз, контроль чарасы уздырыла торган биналарга һәм территорияләргә керү, товарлар күрсәтүне, башкарылган эшләр, күрсәтелгән хезмәтләр нәтиҗәләрен таләп итү;

г) фото-, видео- һәм аудиотехника, шулай ук башка төр техника һәм приборлар, шул исәптән үлчәү приборлары кулланып, түбәндәгеләрне җәлеп итеп, контроль чаралар үткәрү өчен кирәкле экспертизаларны билгеләргә (оештырырга);

бәйсез экспертлар (махсуслаштырылган эксперт оешмалары);

башка дәүләт органнары белгечләре;

контроль органнары карамагындагы учреждениеләр белгечләре;

д) эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру өчен кирәкле дәүләт һәм муниципаль мәгълүмат системаларыннан, хуҗасы яисә операторы тикшереп тору объекты булган мәгълүмат системаларыннан файдалану мөмкинлеген алырга, мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында Россия Федерациясе законнары, дәүләт сере һәм башка саклана торган сер турында Россия Федерациясе законнары үтәлешен тәэмин итеп;

е) контроль объекты эшчәнлеген документаль һәм (яки) фактик өйрәнү буенча чаралар үткәрергә (оештырырга), шул исәптән тикшерү, инвентаризация, күзәтү, яңадан исәпләү, экспертиза, тикшеренүләр, контроль үлчәүләр (үлчәү) юлы белән дә»;

11нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

11. Әлеге Тәртипнең 9 пунктында күрсәтелгән вазыйфаи затлар бурычлы:

а) Россия Федерациясе Бюджет законнары һәм бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган башка хокукый актлар нигезендә эчке дәүләт (муниципаль) финанс контролен гамәлгә ашыру буенча контроль органы вәкаләтләрен үз вакытында һәм тулысынча үтәргә;

б) контроль чаралар үткәрелә торган контроль объектларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәргә;

в) контроль чараларын контроль органының контроль чарасын үткәрү турында хокукый акты нигезендә үткәрергә, кирәк булганда, контроль органы хокукый актының күчермәсен күрсәтеп;

г) контроль чарасы үткәргәндә контроль объекты эшчәнлеген гамәлгә ашыруга комачаулауга юнәлдерелгән гамәлләр кылмаска;

д) тикшерү объекты җитәкчесенә (вәкиленә) контроль органының контроль чарасын үткәрү турында хокукый акты күчермәсе, контроль органының тикшерү чарасын туктатып тору, яңарту һәм озайту турында, тикшерү (ревизия) төркеме составын үзгәртү турында хокукый акты белән, шулай ук контроль чаралар нәтиҗәләре (актлар, бәяләмәләр) белән таныштыру;

е) контроль объектының җитәкчесенә, вазыйфаи затына яисә бүтән хезмәткәренә күчмә тикшерү (ревизия, тикшерү) барышында контроль объектының эшчәнлеген фактта өйрәнү (карау, инвентаризацияләү, күзәтү, яңадан исәпләү, экспертиза, тикшерү, контроль үлчәү) буенча контроль гамәлләр үткәргәндә катнашырга һәм контроль чарасы предметына караган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә комачауламаска.

ж) Россия Федерациясе Бюджет кодексында каралган очракларда, ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр, күрсәтмәләр җибәрергә;

з) Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган очракларда, мәҗбүр итүнең бюджет чараларын куллану турында хәбәрнамәләр җибәрергә;

и) административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә административ хокук бозулар турындагы эшләр буенча эш алып барырга;

к) гавами-хокукый оешмага китерелгән зыянны каплау, сатып алуларны Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда гамәлдә түгел дип тану турында дәгъва гаризалары белән судка мөрәҗәгать итәргә;

л) җинаять составы билгеләре булган гамәлләр кылу фактын ачыклау турында мәгълүматны һәм (яки) мондый фактны раслаучы документлар һәм башка материалларны хокук саклау органнарына җибәрергә;

м) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, дәүләт органы (вазыйфаи зат) адресына мондый орган (вазыйфаи зат) компетенциясенә караган хокук

бозу билгеләрен дәлилләүче хәлләрне һәм фактларны ачыклау турында мәгълүмат һәм (яисә) мондый фактларны раслаучы документлар һәм башка материалларны җибәрергә.».

2. Әлеге карарның 10нчы һәм 11нче пунктлары 01.07.2020 үз кеченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында. (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы җитәкчесенә йекләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров